**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

14.03.2019 Балык Бистәсе штп. № 09ри

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен үзвакытында карау максатларында, 2006 елның 2 маендагы “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау турында” 59-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2003 елның 12 маендагы “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 16-ЗРТ номерлы Законы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибен расларга (кушымта итеп теркәлә).

2. Сишәмбе көнне 8.30 дан 12.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында шәхси мәсьәләләр буенча гражданнарны кабул итү көне итеп билгеләргә.

3. Һәр айның беренче һәм өченче сишәмбеләрендә 8.30 дан 12.00 сәгатькә кадәр гражданнарны шәхси мәсьәләләр буенча кабул итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең гамәлгә ашыруын билгеләргә.

4.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнарны шәхсән кабул итүне гамәлгә ашыруга, шулай ук хатлар-җавапларны имзалауга үзләренең компетенцияләре нигезендә . Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларына вәкаләт бирергә.

5.Җаваплы итеп билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына гражданнарның почта элемтәсе ярдәмендә, электрон документ әйләнеше Системасында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Интернет-кабул итү бүлмәсе аша язма рәвештә кергән мөрәҗәгатьләрен үзвакытында теркәү өчен – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенең баш белгечен;

- гражданнарның язма мөрәҗәгатьләрен үзвакытында карау һәм үтәүгә контроль буенча – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары тарафыннан гражданнарны шәхсән кабул итүне оештыру, гражданнарның телдән бирелгән мөрәҗәгатьләрен үзвакытында карау һәм үтәүгә, гражданнарның “кайнар линия” телефоны буенча кабул ителгән мөрәҗәгатьләрен теркәү һәм үзвакытында карау һәм үтәүгә контроль өчен – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе сәркатибен.

6. Көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 28 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибен раслау турында” 76ри номерлы боерыгын.

7.Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

8. Боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 14 мартындагы
09 ри номерлы боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Әлеге Тәртип Россия Федерациясе гражданнарының язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен (алга таба – мөрәҗәгатьләр) кабул итү, исәпкә алу, теркәү һәм карау, аларны карауга һәм үтәүгә контроль кагыйдәләрен билгели, мөрәҗәгатьләрдәге мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү, мөрәҗәгатьләрнең сәбәпләрен һәм характерын ачыклау, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында (алга таба – Башкарма комитет) гражданнарны кабул итүне оештыру тәртибен тәгаенли.

Әлеге Тәртип нигезләмәләре 2006 елның 2 маендагы “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 59-ФЗ номерлы Федераль законда, Татарстан Республикасының 2003 елның 12 маендагы “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 16-ЗРТ номерлы Законында билгеләнгән тәртиптә каралырга тиешле бөтен мөрәҗәгатьләргә тарала.

1.2.Гражданнарның язма мөрәҗәгатьләре тәкъдимнәр, гаризалар һәм шикаятьләр рәвешендә килә.

Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать юнәлтелгән органның исеме һәм адресы яисә тиңдәшле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме яки тиңдәшле затның вазыйфасы күрсәтелергә тиеш, шулай ук тәкъдим, гариза яки шикаять асылын бәян итү, җавапны, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау хакындагы хәбәрне җибәрергә (кирәк очрак өчен) почта адресы, үзенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), култамгасы һәм датасы булуы зарур.

Электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка килгән мөрәҗәгать 2006 елның 2 маендагы “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Граждан мөрәҗәгатьтә мәҗбүри тәртиптә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы булган сурәттә), җавапны, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау хакындагы хәбәрне җибәрү өчен электрон почта адресын күрсәтә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә электрон формада зарури документларны һәм материалларны теркәргә хаклы.

Гражданнар тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә, үз туган телләрендә яисә Россия Федерациясенең үзләре белгән теләсә кайсы халкы телендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Гражданнарның тәкъдимнәренә, гаризалары, шикаятьләренә җаваплар мөрәҗәгать ителгән телдә бирелә. Җавапны мөрәҗәгать иткән телдә бирү мөмкин булмаган очракта Татарстан Республикасы дәүләт телләре файдаланыла.

1.3. Хәл итү Башкарма комитет компетенциясенә кермәгән сораулар булган язма мөрәҗәгатьләр теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә мөрәҗәгатьтә куелган сораулар компетенцияләренә кергән тиешле органга яки тиешле вазыйфаи затка юллана. Бу вакытта мөрәҗәгать итүче гражданга мөрәҗәгатьне башка адреска юллау хакында, Федераль законның 11 маддәсенең 4 өлешендә күрсәтелгән очрактан гайре, язма хәбәр бирелә. Шуның белән бергә хәбәр текстында Законның тиңдәшле маддәсенә күрсәтү, таяну булырга тиеш. Белдерү хәбәренең икенче нөсхәсе делога теркәлә.

Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозулар ихтимал булган фактлар турында мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгать теркәү көненнән соң биш көн эчендә

эчке эшләр өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының 2 территориаль органына һәм Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә. Бу вакытта мөрәҗәгать итүче гражданга мөрәҗәгатьне башка адреска юллау хакында, Федераль законның 11 маддәсенең 4 өлешендә күрсәтелгән очрактан гайре, язма хәбәр бирелә.

Язма мөрәҗәгатьтәге куелган сорауларны хәл итү берничә дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат компетенциясенә карау очрагында мөрәҗәгать күчермәсе теркәлү көненнән соң җиде көн эчендә тиңдәшле дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә тиешле вазыйфаи затларга җибәрелә.

1.4. Шикаятьне карарларына яки гамәл кылуларына (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат каравына җибәрү тыела.

Әгәр әлеге тыю белән бәйле рәвештә шикаятьне мөрәҗәгатьтә куелган сорауларны хәл итү компетенциясенә кергән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрү мөмкин булмаса, шикаять, тиңдәшле карарга яки гамәл кылуга (гамәл кылмауга) билгеләнгән тәртиптә аның судка шикаять белдерергә хокукларын аңлатып, гражданга кире кайтарыла.

1.5. Язма мөрәҗәгать текстын укып булырлык булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул компетенцияләренә туры килгән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи зат каравына да җибәрелми, ул турыда мөрәҗәгать теркәлгән көннән соң җиде көн эчендә, әгәр фамилиясен һәм почта адресын укып булырлык булса, мөрәҗәгатьне юллаган гражданга хәбәр ителә. Күрсәтелгән мөрәҗәгать делога теркәлә.

1.5.1. Язма мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гариза яисә шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәгән очракта мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул компетенцияләренә туры килгән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи зат каравына да җибәрелми, ул турыда мөрәҗәгать теркәлгән көннән соң җиде көн эчендә мөрәҗәгатьне юллаган гражданга хәбәр ителә.

1.6. Мөрәҗәгатьне җибәргән гражданның язма мөрәҗәгатьтә фамилиясе яки җавап юлланырга тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, аңа җавап бирелми. Мондый мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба – Башкарма комитеты җитәкчесе) карары белән тиешле делога теркәлә яки билгеләнгән тәртиптә юк ителә.

Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгать хокукка каршы эш әзерләнү, аның эшләнүе яки булганлыгы хакында мәгълүматны үз эченә алса, шулай ук аларны эшләүче, башкаручы зат турында мәгълүмат булса, мөрәҗәгать компетенциясенә туры килгән тиңдәшле дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

1.7. Гражданнар Башкарма комитетка, Башкарма комитетның вазыйфаи затларына үзләренең вәкилләре аша да мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.8. Суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгать теркәлгән көненнән соң җиде көн эчендә, әлеге хөкем карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать юллаган гражданга кире кайтарыла.

1.9.Әгәр килгән мөрәҗәгатьтә Башкарма комитетның вазыйфаи затына, шулай ук аның гаилә әгъзаларына карата ярамаган яисә кимсетүле тәгъбирләр, тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау, өркетү булса, андагы куелган сораулар белән бергә мөрәҗәгать асылда җавапсыз калдырылырга мөмкин. Әлеге очракта мөрәҗәгать юллаган гражданга мөрәҗәгать итү хокукыннан явызларча файдалануның һич тә ярамаганлыгы хакында хәбәр ителә.

1.10. Гражданның язма мөрәҗәгатендә элек юлланган мөрәҗәгатьләре белән бәйле нигез буенча күп тапкырлар язма рәвештә җавап бирелгән сорау булган очракта, шуның белән бергә мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр китерелмәсә яисә яңа хәлләр булмаса, Башкарма комитет җитәкчесе әлеге мөрәҗәгать һәм элек юлланганнары да Башкарма комитетка яисә бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән сурәттә чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсезлеге хакында һәм әлеге мәсьәлә буенча граждан белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы.Әлеге карар хакында мөрәҗәгать юллаган гражданга хәбәр ителә.

1.10.1. Башкарма комитетка яки вазыйфаи затка 2006 елның 2 маендагы “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсенең 4 өлеше һәм әлеге Тәртипнең 2.12 пунктының бишенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында җавап урнаштырылган сорауны үз эченә алган язма мөрәҗәгать кергән очракта мөрәҗәгать юллаган гражданга мөрәҗәгать теркәлгән көннән соң җиде көн эчендә мөрәҗәгатьтә кузгатылган сорауга җавап урнаштырылган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, шуның белән бергә хөкем карарына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгать кире кайтарылмый.

1.11. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауга чынлыкта дәүләт серен яисә федераль законнар белән саклanучы серне тәшкил итүче мәгълүматларны фаш итмичә җавап бирү мөмкин булмаган очракта мөрәҗәгать юллаган гражданга ул куйган сорауга асылда күрсәтелгән мәгълүматларны ачып салу рөхсәт ителмәү сәбәпле җавап бирү мөмкин түгеллеге хакында хәбәр ителә.

*

**2. Гражданарның язма мөрәҗәгатьләрен кабул итү, теркәү һәм исәпкә алу**

2.1. Почта аша җибәрелеп, булуы мөмкин булган шартлаучан, агулы һәм салынган башка куркыныч нәрсәләрне үзвакытында белү, ачыклау һәм зарарсызландыру максатларында почтадан килгән әйберләргә тышкы тикшерү уздырыла. Почтадагы андый әйберләрнең беленүе яки аларның булуына шик туу очрагында почта аша килгән әйберләр белән алга таба теләсә нинди эш итү кичекмәстән туктатыла һәм иминлек органының тиңдәшле подразделениесеннән белгеч чакыртыла. Белгеч чакыртылу белән бер үк вакытта почтадан килгән әйберне мәҗбүри рәвештә изоляциялэп иминлек чаралары күрелергә тиеш.

Террорлык актлары һәм башка җинаятьләр кылу куркынычы турындагы язма мөрәҗәгатьләрне алганда оператив-эзләү чаралары һәм тикшерү гамәлләре үткәргәндә файдаланырга мөмкин булган андагы ихтимал эзләрне саклау өчен чаралар күрелә.

2.2. Язма мөрәҗәгатьләрне кабул иткәндә аларның адресларының дөреслеге тикшерелә. Аталышы буенча китерелмәгән хатлар тиз арада адресатына юллау өчен ачылмаган килеш элемтә почтасы предприятиесенә кайтарыла.

Конвертларны ачканда аларда хат һәм документларның булуы тикшерелә (ертылган документлар ябыштырыла), алар конвертка кыстыргыч белән беркетеләләр, булган документлар (паспорт, хәрби билет, хезмәт кенәгәсе, пенсия таныклыгы һ.б.лар, шулай ук фотографияләр һәм хатка бүтән өстәмәләр) хат тексты өстенә кыстыргыч белән беркетелә. Өстәмәнең яисә хат текстының үзенең булмавы беленгән очракта белешмә язылып конвертка теркәлә һәм ул турыда хәбәр итүчегә җиткерелә.

2.3. Бөтен язма мөрәҗәгатьләр Башкарма комитетка кергән мизгелдән соң өч көн эчендә теркәләләр. Һәрбер мөрәҗәгатькә тәртип буенча теркәү номеры бирелә. Һәр килгән яңа календарь елда яңа кергән мөрәҗәгатьләрне нумерацияләү беренче номердан башлана. Теркәгәннән соң барлык мөрәҗәгатьләргә дә аларда мәгълүматның булуына алдан карап чыгу оештырыла. Әлеге процедураның максаты булып Башкарма комитетка гражданнарның коррупция фактлары буенча кергән мөрәҗәгатьләренең санын ачыклау тора.

Барлык кергән корреспонденциядән мөмкин булган коррупцион хокук бозулар (үзидарәлек хезмәткәрләренең кылган гамәлләре (гамәл кылмаулары) вазыйфаи хәлен акча, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт яки мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр, үзе яисә өченче затлар өчен мөлкәт хокуклары рәвешендә файда алу максатларында гражданнарның законлы мәнфәгатьләренә каршы законсыз файдалану белән бәйле булуына күрсәтүче фактик мәгълүматлар) турында мәгълүматы булган мөрәҗәгатьләр күрсәтелә (ачыклана).

Әлеге процедура Тәртипнең 3 бүлегендә күз алдында тотылган аерым тәртиптә каралучы мөрәҗәгатьләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

2.4.Язма мөрәҗәгатьләргә резолюцияләр бергә җибәрелә торган хатның сулъяк югарыгы почмагында яисә мөрәҗәгать итүче хатының беренче битендә рәсмиләштерелә. Резолюциядә вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, резолюция тексты (зарурлык булганда – конкрет күрсәтмәләр һәм үтәү датасы белән), имза һәм дата булырга тиеш.

2.5.Җитәкче резолюциясендә берничә башкаручы күрсәтелсә, хатта куелган бөтен сорауларны да үтәү өчен җаваплы булып исемлектә беренче урындагы башкаручы тора.

2.6.Башкарма комитетка кәгазь мәгълүмат йөрткечтә килгән язма мөрәҗәгатьләр мәҗбүри рәвештә сканерлана һәм электрон документ әйләнеше Системасына кертелә.

2.7. Граждан шикаятендә күрсәтелгән мәгълүматлар ахыргы карарны чыгару өчен җитәрлек булмаганда, гамәлләренә шикаять бирелә торган учреждение яисә заттан карар кабул итүнең нигезле булуы хакында бәяләмә белән тикшерү материаллары соратып алдырыла. Зарурлык булган очракта Башкарма комитет Җитәкчесе күрсәтмәсе буенча шикаятьне урында тикшерү өчен Башкарма комитет хезмәткәрләре командировкага җибәрелергә мөмкин.

2.8. Гражданнарның хатлары, алардагы бөтен сораулар да каралып, алар буенча кирәкле чаралар күрелсә һәм гамәлдәге законнарга туры килүче тулы җаваплар бирелгәндә хәл ителгән булып санала.

2.9. Мөрәҗәгатькә әзерләнгән җавап проектына башкаручы тарафыннан сулъяк аскы почмакка виза салына һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә, компетентлыкларына ярашлы рәвештә аның урынбасарларына тапшырыла.

Башкаручы (кул куючы затлар белән бер үк вакытта) җавапларның эчтәлеге, аларның ачык аңлаешлы һәм төгәл бәян ителүе, норматив актларга сылтамаларның дөрес, ышанычлы булуына җаваплылык тота.

2.10. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары:

а) мөрәҗәгатьне объектив, төрлеяклап һәм үзвакытында карауны тәэмин итәләр, зарурлык булганда – мөрәҗәгатьне юллаган граждан катнашында;

б) мөрәҗәгатьне карау өчен, шул исәптән электрон рәвештә дә, кирәкле документларны башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм бүтән вазыйфаи затлардан, судлар, сорау алуны үткәрү органнарыннан һәм алдан тикшерү органнарыннан гайре, соратып алдыралар.

в) гражданның бозылган хокукларын, ирек һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау һәм торгызуга юнәлдерелгән чаралар күрәләр;

г) мөрәҗәгатьтә куелган, әлеге Тәртипнең1.5, 1.5.1, 1.6, 1.8, 1.9, 1.10, 1.10.1, 1.11 пунктларында күрсәтелгән очраклардан гайре, сорауларның асылы буенча язма рәвештә җаваплар бирәләр;

д) гражданга мөрәҗәгатен компетенцияләренә туры килүче башка дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә бүтән вазыйфаи затка карауга җибәрелүе хакында хәбәр итәләр.

2.11. Мөрәҗәгатьне караганда андагы мәгълүматларны, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы мәгълүматларны үзенең ризалыгыннан башка читкә чыгару рөхсәт ителми.

Мөрәҗәгатьтә куелган сорауларны хәл итү компетенциләренә кергән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне юллау мөрәҗәгатьтәге мәгълүматларны фаш итү булып тормый.

2.12. Гражданнарның Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә ярашлы рәвештә килгән язма мөрәҗәгатьләре, Федераль законның 12 маддәсенең 1.1 өлешендә күрсәтелгән очрактан гайре, теркәлгән көннән соң 30 көн эчендә карала.

2.13. Башкарма комитетка кергән һәм үтәү өчен Башкарма комитет подразделениеләренә тапшырылган мөрәҗәгатьләрне карау срогының башлануы булып аларны теркәү көне санала.

Мөрәҗәгатьләрне карау срогының ахыры булып мөрәҗәгать авторына җавапны имзалау датасы санала.

2.14.Билгеләнгән тәртиптә каралган мөрәҗәгатьләр буенча кабул ителгән карарлар хезмәт урынындагы таратылуы чикләнгән мәгълүмат исәбенә кертелә алмыйлар.

Мөрәҗәгатьтә куелган сорауга җавап бирү нигездә дәүләт яисә федераль закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче мәгълүматларны ачып салудан башка гына мөмкин булмаган очракта мөрәҗәгатьне юллаучы гражданга анда куелган сорауның асылы буенча күрсәтелгән мәгълүматларны тарату ярамаганлыгы сәбәпле җавап бирү мөмкин булмавы турында хәбәр ителә.

2.15.Язма мөрәҗәгатькә җавап Башкарма комитет бланкында әзерләнә һәм Башкарма комитет Җитәкчесе, компетенцияләренә ярашлы рәвештә аның урынбасарлары тарафыннан имзалана. Җавап граждан күрсәткән адреска җибәрелә.

Ике яки берничә зат мөрәҗәгатенә (күмәк мөрәҗәгать) җавап мөрәҗәгатьтә җавапны алучы сыйфатында күрсәтелгән затка яисә мөрәҗәгатькә кул куйган гражданнар коллективы вәкиленә юллана. Әгәр күмәк мөрәҗәгатьтә җавап алучы тәгаенләнмәсә, җавап мөрәҗәгать итүчеләр (кул куючылар) исемлегендә беренче торучы һәм үзенең яшәү урынының адресын күрсәткән гражданга җибәрелә. Күмәк мөрәҗәгатькә җавапны җибәрү хакында үтенеч берничә мөрәҗәгать итүче (кул куючы) зат тарафыннан белдерелгән очракта җавап күчермәләре аларның күрсәткән почта адреслары буенча һәрберсенә җибәрелә.

Мөрәҗәгатькә җавап Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә килгән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә һәм Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка язма рәвештә килгән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә юллана.

Шуның өстенә Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка килгән билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылган тәкъдимне, гариза яки шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган хөкем карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән хөкем карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, 2006 елның 2 маендагы “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 59-ФЗ номерлы Федераль законның 6 маддәсенең 2 өлеше һәм әлеге Тәртипнең 2.9 пункты таләпләрен үтәп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

## 3. Гражданнарның коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләре белән эш итү тәртибе

3.1. Коррупцион хокук бозулар мөмкинлеге турында мәгълүмат күрсәтелгән мөрәҗәгатьне алдан карау процедурасы үткәрелгәннән соң мөрәҗәгать кичекмәстән Башкарма комитет Җитәкчесенә тапшырыла.

Башкарма комитет Җитәкчесе резолюция сала һәм башкаручыларны билгели. Мөрәҗәгатьне карау аерым контрольгә куела.

3.2.Мөрәҗәгать карары яки гамәл кылуы (гамәл кылмавы) мөрәҗәгать темасы булып торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка юлланмый.

3.3. Мөрәҗәгатьтә әзерләнүче, бара торган яки булып үткән законга сыймаучы эш турында, шулай ук андый эшне әзерләүче, башкара торган һәм башкарган зат турында мәгълүматлар булган очракта мөрәҗәгать теркәлә һәм компетенциясенә ярашлы рәвештә тиешле дәүләт органына юллана.

3.4. Мөрәҗәгатьтә үзидарәлек хезмәткәре тарафыннан үзидарәлек хезмәте белән бәйле вазыйфаларны, чикләүләр һәм тыюларны, шулай ук хезмәт урыны белән бәйле тәртипкә таләпләрне үтәмәү турында, үзидарәлек хезмәткәрендә мәнфәгатьләр низагына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну булу турында, мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү турында, үзидарәлек хезмәткәре тарафыннан башка коррупцион хокук бозулар кылыну мөмкинлеге турында мәгълүматлар булган очракта Башкарма комитет Җитәкчесе коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны кисәтү буенча кадрлар хезмәте подразделениесенең вазыйфаи заты (коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы вазыйфаи затларның) мәгълүматнамәсе нигезендә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактларга карата тикшерү үткәрүнең максатка ярашлылыгы турында карар кабул итә.

Әлеге тикшерү хезмәт урыны белән бәйле тәртипкә таләпләрне үтәүне (үзидарәлек хезмәткәре тарафыннан чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр низагын булдырмый калу яки көйләү турындагы таләпләрне, 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы тору турында" 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган бурычларны үтәвен) тикшерү булып тора һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә үткәрелә.

3.5. Мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар оператив-эзләнү чаралары үткәрү ярдәмендә тикшерүгә мохтаҗ булган очракта мөрәҗәгатьне карау процессында оператив-эзләнү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт органына запрос юллана.

3.6. Күрсәтелгән тикшерүне үткәргәндә үзидарәлек хезмәткәре тарафыннан хезмәт урыны белән бәйле тәртипкә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәү турында таныклаучы фактлар расланган очракта Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан тикшерү материалларын үзидарәлек хезмәткәрләренең хезмәт урыны белән бәйле тәртипкә таләпләрне һәм "Балык Бистәсе муниципаль районы" үзидарәлек берәмлегенең җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр низагын җайга салу турында таләпләрне үтәү буенча Комиссиягә (алга таба – Комиссия) бирү турында карар кабул ителә.

Комиссия утырышында күрсәтелгән сорауны карау турында карар кабул иткәндә утырышның датасы, вакыты һәм урыны билгеләнә, шулай ук норматив хокукый актлар нигезендә Комиссия утырышын әзерләү буенча эш оештырыла.

3.7. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча мөрәҗәгать итүчегә җавап үз эченә үткәрелгән чараларның һәм тикшерүләрнең нәтиҗәләре турында, Комиссия карарлары турында (булганда) мәгълүматны, шулай ук күрелгән чаралар, шул исәптән үзидарәлек хезмәткәренә җаваплылык чаралары куллану турында яисә тикшерү үткәрү өчен нигез булмавы турында һәм коррупция фактларының расланмавы турында мәгълүматны алырга тиеш.

3.8. Гражданнарның коррупция юнәлешендәге фактлар буенча Башкарма комитетка килгән мөрәҗәгатьләре әлеге Тәртип белән билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

3.9. Гражданга мөрәҗәгатьтә куелган барлык сорауларга җавап җибәрелгәннән соң мөрәҗәгать контрольдән төшерелә.

## 4. Гражданнардан "кайнар линия" телефоны буенча кабул ителгән мөрәҗәгатьләрне карау

4.1. Әлеге бүлек Башкарма комитеттагы "кайнар линия" телефонының (алга таба – "кайнар линия") эш тәртибен, килгән мөрәҗәгатьләрне кабул итү, теркәү һәи исәпкә алу тәртибен билгели.

4.2. "Кайнар линия" телефоны буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен кабул итү һәр пәнҗешәмбе (бәйрәм көннәреннән гайре) 8.30 дан 12.00 гә һәм 13.30 дан 16.30 га кадәр (884361) 22-500 номеры буенча гамәлгә ашырыла.

4.3. "Кайнар линия" телефонының эшләве һәм эш режимы турындагы мәгълүмат халык игътибарына гаммәви мәгълүмат чаралары аша Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына һәм ТР, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт адресы буенча Башкарма комитет бинасы вестибюлендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән җиткерелә.

4.4. Гражданнарның "кайнар линия" телефоны аша Башкарма комитетка килгән мөрәҗәгатьләре мәҗбүри теркәлергә тиешле.

4.5. Гражданнарның "кайнар линия" телефоны аша мөрәҗәгатьләрен кабул итү һәм теркәүне әлеге Тәртип нигезендә Башкарма комитет җитәкчесенең сәркатибе (алга таба – сәркатип) гамәлгә ашыра.

Гражданнарның "кайнар линия" телефонына мөрәҗәгатьләрен исәпкә алу өчен исәпкә алу журналы файдаланыла, анда гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы –

булганда), яшәү урынының адресы, соравының кыскача эчтәлеге һәм карау нәтиҗәсе күрсәтелә.

4.6. Гражданнарның хөкем карарына шикаять бирелә торган, конкрет фактлары булмаган мәгълүмат, шулай ук кимсетү характерындагы мәгълүмат ирештерүче телефон аша мөрәҗәгате теркәлми.

4.7.Гражданнарга мәгълүмат бирү алар тарафыннан персональ мәгълүматлары (фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы – булганда), телефон номеры, зарурлык булганда җавап юлларга тиешле почта адресы) тапшырылып, мөрәҗәгатенең асылын бәян иткәннән соң гамәлгә ашырыла.

4.8.Телефон аша кабул ителгән хәбәр 1 Кушымтага туры китереп “”кайнар линия” буенча алынды, датасы, вакыты” тамгасын салып язма рәвештә сәркатип тарафыннан рәсмиләштерелә һәм Башкарма комитет каравына юллана.

Аның буенча алга таба эш гражданнарның язма мөрәҗәгатьләрен карау өчен күздә тотылган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4.9. Һәрбер квартал, яртыеллык, ел йомгаклары буенча хисап бирелә торганы артыннан килүче айның 15 нче числосына кадәрге срокта сәркатип Башкарма комитет җитәкчесенә гражданнардан телефон аша кергән хәбәрләрнең саны, характеры һәм сәбәбе, аларны карау буенча күрелгән чаралар турында хисап тапшыра.

4.10. Гражданнардан телефон аша кергән мөрәҗәгатьләре белән бәйле материаллар һәм исәпкә алу журналлары эш башкару кагыйдәләренә ярашлы рәвештә 3 ел Башкарма комитетта саклана, ә аннан соң билгеләнгән тәртиптә юк ителә.

## 5. Гражданнарны шәхсән кабул итүне оештыру

5.1 Гражданнарны шәхсән кабул итү Башкарма комитет Җитәкчесе, аның урынбасарлары тарафыннан үткәрелә.

5.2. Район Башкарма комитетында гражданнарны кабул итү өчен махсус кабул итү бүлмәсе билгеләнә.

Кабул итү урыны, кабул итү өчен тәгаенләнгән көннәр һәм сәгатьләр, вазыйфаи затлар, гражданнарны кабул итүне әзерләү өчен җаваплы кешеләрнең контакт телефоннары турында мәгълүмат гражданнар игътибарына гаммәви мәгълүмат чаралары аркылы җиткерелә һәм Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук ТР, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт адресы буенча Башкарма комитет бинасы вестибюлендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Кабул итү үткәрелә торган бинада гражданнарны кабул итүгә турыдан –туры мөнәсәбәте булмаган затларга булу тыела.

Аерым очракларда гражданнарны кабул итү Башкарма комитет Җитәкчесенең, аның урынбасарларының эш кабинетларында гамәлгә ашырылырга мөмкин. Зарурлык булганда очрашулар гражданнарның яшәү яисә эш урыннарында оештырыла.

. 5.3.Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең кабул итү бүлмәсендә телдән мөрәҗәгать итүләрнең эчтәлеге гражданны шәхсән кабул итү карточкасына (кушымта №2) кертелә, анда гражданны кабул итү датасы, аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), тору урынының адресы, кабул итүне алып баручы вазыйфаи (вәкаләтле) затның фамилиясе, телдән мөрәҗәгатьнең эчтәлеге һәм аның буенча күрелгән чаралар турында мәгълүматлар язылырга тиеш. Күрсәтелгән реквизитлар кирәкле бүтән мәгълүматлар белән тулыландырылырга мөмкин.

5.4. Гражданнарны шәхсән кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә беренче чиратта шәхсән кабул ителү хокукына ия:

1) I, II төркем инвалидлар һәм (яки) аларның законлы вәкилләре (әти-әниләрнең, уллыкка алучыларның берсе, опекун яки попечитель);

2) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы

Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары;

3) инвалид, ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм балалар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм мондый балаларның хокукларын һәи законлы мәнфәгатьләрен яклау һәм тәэмин итү белән бәйләнгән сораулар буенча мөрәҗәгать иткәндә аларның вәкилләре;

4) өч яшькә хәтле булган балалары белән кабул итүгә килгән гражданнар.

5.5. Граждан шәхсән кабул итүдә шәхесен таныклаучы документын тәкъдим итә. Андый документын тәкъдим итүгә граждан каршы килгән очракта аның мөрәҗәгате аноним буларак санала. Шәхсән кабул итүдә әлеге Тәртипнең 5.4. пунктының 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар беренче чиратта кабул ителүгә хокукларын раслаучы документны күрсәтәләр. Бер үк вакытта беренче чиратта кабул ителүгә хокуклары булган берничә граждан туры килгән очракта күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхсән кабул итүгә килеп җитүләре тәртибендә гамәлгә ашырыла.

5.6.Кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи (яисә вәкаләтле) зат гражданны игътибар белән тыңларга һәм мөрәҗәгатенең асылына җентекле төшенергә бурычлы. Телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр аермачык күренеп тора торган булып өстәмә тикшерү таләп итмәсәләр, мөрәҗәгатькә җавап граждан ризалыгы белән шәхсән кабул итү барышында бирелергә мөмкин, ул турыда гражданны шәхсән кабул итү карточкасында язылып куела һәм гражданның имзасы белән раслана. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларга асылда язма рәвештә җавап бирелә.

Шәхсән кабул итү барышында кабул ителгән язма мөрәҗәгать теркәлергә һәм Федераль законда һәм әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Зарур очракларда гражданның телдән мөрәҗәгате нигезендә язма мөрәҗәгатьләр өчен билгеләнгән тәртиптә теркәлә торган белешмә төзелә.

Мөрәҗәгатьтә хәл ителүе Башкарма комитет компетенциясенә керми торган сораулар булган очракта гражданга кая һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәклеге аңлатыла.

Әгәр элегрәк мөрәҗәгатьтә кузгатылган сорауларга нигездә җавап бирелгән булса, шәхсән кабул итү барышында гражданга алга таба мөрәҗәгатьне карау кире кагылырга мөмкин.

5.7.Башкарма комитетның вазыйфаи затлары гражданнарны шәхсән кабул итү белән бәйле сораулар буенча җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре аларга ярдәм итәргә һәм булышлык күрсәтергә (кирәкле белешмә һәм мәгълүмати материалларны бирергә (норматив хокукый актлар нигезендә таратылырга (фаш ителергә) тиеш булмаган мәгълүматлардан гайре), квалификацияле консультацияләр, элемтә белән тәэмин итәргә, кабул итүне гамәлгә ашыру өчен хезмәткәрләр җибәрергә һ.б. ны эшләргә) тиешле бүтән җирле үзидарә органнарына, предприятие, учреждение яисә оешмаларга мөрәҗәгать итәргә хокуклы

5.8.Кабул итү вакытында граждан әйләнә-тирәдәгеләр тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч яный торган гамәләр кылу очрагында кабул итүне алып баручы вазыйфаи (вәкаләтле) зат Россия Федерациясе законнары нигезендә кирәкле чараларны күрә. Зарурлык булганда эчке эшләр органнары һәм ашыгыч медицина ярдәме хезмәткәрләре чакыртыла.

## 6. Мөрәҗәгатьләр белән эш итүнең торышын тикшерү һәм аларны карауга контроль. Мөрәҗәгатьләрдәге мәгълүматка анализ һәм гомумиләштерү.

6.1. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары үзләренең компетенцияләре чикләрндә мөрәҗәгатьләрне карау тәртибен үтәүгә контрольне гамәлгә ашыралар, кергән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеген анализлыйлар, гражданнарның хокуклары, ирек һәм законлы мәнфәгатьләренең бозылу сәбәпләрен үзвакытында ачу һәм бетерү буенча чаралар күрәләр.

6.2.Кварталга кимендә бер тапкыр мөрәҗәгатьләрне карау һәм алар буенча карарлар кабул итү эшенә эчке тикшерү уздырыла, аның өчен Башкарма комитет җитәкчесе боерыгы белән комиссия төзелә. Тикшерү йомгаклары буенча мөрәҗәгатьләрне карау тәртибен бозу беленгән очракта аларны бетерү һәм гаепле затларны җавапка тарту буенча тәкъдимнәрне үз эченә алырга тиешле акт төзелә

6.3. Башкарма комитетта үтәлү сроклары буенча барлык язма мөрәҗәгатьләр, шулай ук гражданнарны шәхсән кабул итүдәге карау нәтиҗәләре турында авторга җавап бирү яисә тиңдәшле орган яки вазыйфаи зат запросы буенча мәгълүмат бирү таләп ителә торган мөрәҗәгатьләр контрольдә торырга тиеш.

6.4. Контроль буенча турыдан-туры эш Башкарма комитетның контроль буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи затларына йөкләнә. Мондый контрольне гамәлгә ашыручы затлар хокуклы:

а) башкаручылардан һәм аларның турыдан-туры җитәкчеләреннән мөрәҗәгатьләрне карау барышы хакындагы кирәкле мәгълүматларны соратып алдырырга;

б) мөрәҗәгатьләрне карау торышын чагылдыручы материаллар белән билгеләнгән тәртиптә танышырга;

в) мөрәҗәгатьләрне карауга контрольлек итү барышында билгеле булган җитешсезлекләрне бетерү буенча тиешле вазыйфаи затларга тәкъдимнәр кертергә;

6.5. Мөрәҗәгатьләрне карауга контрольлек итү барышы хакында даими рәвештә (тик айга кимендә бер мәртәбәдән дә ким түгел) район Башкарма комитеты Җитәкчесенә хәбәр җиткерелә.

6.6. Гражданнардан мөрәҗәгатьләр килүгә тәэсир итүче сәбәпләрне ачыклау һәм юк итү максатларында, район Башкарма комитеты Җитәкчесе эшчәнлеге хакында еллык хисап әзерләгәндә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ һәм гомумиләштерү үткәрелә. Күрсәтелгән анализ кергән, бүтән адреска юлланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ рәвешендә мөрәҗәгать итүләр саны, гражданнарны кабул итүнең урыннары, көн һәм сәгатьләре турында, шәхсән кабул итүдә булган гражданнар саны турында, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм урыннарга чыгып шәхсән кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләрне карау йомгаклары буенча күрелгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм бүтән актлар (булса) турында мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

6.7. Мөрәҗәгать итүләр белән эшнең торышы (гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ) район Башкарма комитеты җитәкчесе эшчәнлеге турында еллык хисапларда чагылдырыла һәм мәҗбүри тәртиптә (теркәлүче 3, 4 номерлы кушымталар рәвешендә) Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

6.8.Аналитик эш Башкарма комитетның барлык подразделениеләренең тыгыз хезмәттәшлегендә алып барыла.

Гражданнар почталарын караучы белгечләр даими рәвештә тематик язулар, бүтән аналитик материаллар язу өчен үзләренә беркетелгән территорияләр буенча материалларны сайлап алуны һәм туплауны алып баралар (мөрәҗәгатьләрнең, җавапларның күчермәләрен алалар һ.б.), аналитик материаллар төзү өчен үзвакытында кирәкле мәгълүмат әзерлиләр.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибенә кушымта №1

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитеты
Җитәкчесе
_____________________

“КАЙНАР ЛИНИЯ” ТЕЛЕФОНЫНА ГРАЖДАН МӨРӘҖӘГАТЕ

“Кайнар линия” буенча алынды: __________________20__ел. ___ сәг. __ мин

Гражданның “кайнар линия” телефонына килгән мөрәҗәгате турында хәбәр итәм.

Фамилия_________________________________________________________________

Исем _____________________________________________________________________

Атасының исеме (булганда)__________________________________________________

Телефон номеры___________________________________________________________

Почта адресы______________________________________________________________

Мөрәҗәгатьнең эчтәлеге
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
________________

Җаваплы хезмәткәр _____________________ (______________________________)
(имза, дата) .имзаның расшифровкасы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибенә кушымта №2

Район______________________________________
Адрес______________________________________

ГРАЖДАННАРНЫ ШӘХСӘН КАБУЛ ИТҮ КАРТОЧКАСЫ

№_______ Кабул итү датасы "_____"_____________20____ел

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы булганда)________________________________________________________
__________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________
Социаль хәле______________________________________________
Ташламалы состав ___________________________________________________
Кабатлану: әйе, юк ________________________________________________
Әңгәмәнең
эчтәлеге_________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________
_________
Кабул итүнең нәтиҗәсе
__________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________
__
Кабул итүне алып барды ________________________________________________________
Имза ___________________________________________________________

Телдән җавапка риза ____________________________________________
Имза ___________________________________________________________

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибенә кушымта №3

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында

**СТАТИСТИК МӘГЪЛҮМАТЛАР**

| Мәгълүматларның исеме | Цифрлы мәгълүматлар | |
|---|---|---|
| | ______ел | _____ел |
| Кергән мөрәҗәгатьләр **барысы**<br>(хат, шәхсән кабул итү, электрон мөрәҗәгатьләр) | | |
| ш.и. электрон мөрәҗәгатьләр (Интернет, электрон почта) | | |
| ш.и. шәхсән кабул итүдә алынды: | | |
| җитәкче тарафыннан | | |
| урынбасарлары тарафыннан | | |
| Контрольгә алынды | | |
| Уңай хәл ителде | | |
| Урынга барып тикшерелде | | |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибенә кушымта №4

Гражданнардан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына
килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләүнең торышы турында
МӘГЪЛҮМАТЛАР

| Мөрәҗәгать не алучы-адресат | Мөрәҗәгатьләр саны | | | Карауның нәтиҗәләре | | | | Мөрәҗәгатьләр керде түбәндәге мәсьәләләр буенча: | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | барысы | язма рәвештә | телдән | аңлатылды | канәгатьләндерелде | кире кагылды | каралу стадиясендә | сәнәгать | төзелеш | агросәнәгать комплексы | транспорт | элемтә | Финанслар һәм банклар эшчәнлеге | мәгариф, фән һәм мәдәният | сәламәтлек саклау | хакимият һәм җирле үзидарә органнары эше | эчке эшләр органнары | суд, прокуратура, юстиция органнары эше | сәүдә, туклану, көнкүреш хезмәте | коммуналь хуҗалык | социаль, соцтәэмин итү | торак | дин | хезмәт хакы түләү | хезмәт, мәшгульлек | төрлеләр | БАРЛЫГЫ |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче вазыйфасының исеме____________________

(имза) (имзаның расшифровкасы)